РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«7» февраль 2022 ел г. Альметьевск № 159

Җәмәгать эшләрен оештыру турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1997 елның 14 июлендәге 875 номерлы «Иҗтимагый эшләрне оештыру турындагы нигезләмәне раслау турында» карары, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2013 елның 11февралендәге 52н номерлы боерыгы белән расланган түләүле җәмәгать эшләрен уздыруны оештыру буенча дәүләт хезмәтенең федераль дәүләт стандарты, «Татарстан Республикасында җәмәгать эшләрен оештыру турында» 2009 елның 24 февралендәге 99 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә торган җәмәгать эшләренең төп төрләре исемлеге» белән бергә) нигезендә, эшсез гражданнарны һәм эшсез халыкны эшкә урнаштыру мөмкинлеген киңәйтү, аларның һөнәри яраклашуы максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елда Әлмәт муниципаль районы предприятиеләрендә, учреждениеләрендә һәм оешмаларында эшсез гражданнар һәм эш белән тәэмин ителмәгән халык өчен җәмәгать эшләрен оештырырга(1 нче кушымта).

2. «Әлмәт шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (Мирвәлиева Л.С.) тәкъдим итәргә:

- эш бирүчеләр белән җәмәгать эшләрен оештыру һәм уздыру буенча уртак эшчәнлек турында шартнамәләр төзергә;

- 450 кеше күләмендә эшсез гражданнарны һәм эш белән тәэмин ителмәгән халыкны җәмәгать эшләренә эшкә урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Җәмәгать эшләрен оештыру һәм уздыру буенча уртак эшчәнлек турында шартнамә төзегән эш бирүчеләргә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- гражданнар тарафыннан эшкә җибәрелә торган вакытлы хезмәт шартнамәләре төзүне тәэмин итәргә;

- «Әлмәт шәһәре халкын эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан оештырыла торган җәмәгать эшләрендә катнашу өчен җибәрелгән гражданнарга хезмәткә түләүне, эш бирүчедә гамәлдә булган хезмәт өчен түләүнең Россия Федерациясендә түләүнең минималь күләменнән кимрәк булмаган күләмгә туры китереп, фактта эшләнгән яисә башкарылган эшкә түләүне башкарырга;

- хезмәт иминлеген һәм хезмәт гигиенасы таләпләренә җавап бирә торган шартларны һәм хезмәт законнары һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларда каралган кабул ителгән хезмәткәрләргә карата башка йөкләмәләрне үтәүне тәэмин итәргә;
- җәмәгать эшләрен оештырган һәм уздырган өчен җаваплы затларны билгеләргә.

4. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«7» февраль 2022 ел №159
карары белән расланган
1 нче кушымта

2022 елда эшсез гражданнар һәм эш белән тәэмин ителмәгән халык өчен түләүле җәмәгать эшләрен оештыруда һәм үткәрүдә катнашучы Әлмәт муниципаль районы предприятиеләре, учреждениеләре һәм оешмалары исемлеге

| №№ п/п | Предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар исемнәре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 1. | «Әлмәт районы кулланучылар җәмгыятенең Елховой» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 2. | «Васильевская» җаваплылыгы чикләнгән авыл хуҗалыгы җәмгыяте (килешү буенча) |
| 3. | «Табыш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 4. | «Алсу» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) |
| 5. | «Авыл хуҗалыгы-Первомайский» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 6. | «Альянс» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 7. | «Татнефтедор» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 8. | «Спартак» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 9. | «Автомобиль юллары шәһәр идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе (килешү буенча) |
| 10. | «Светсервис» муниципаль унитар предприятиесе (килешү буенча) |
| 11. | «Аппак» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 12. | «Әлмәт инженер-төзелеш компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 13. | «Алсу 2 идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 14. | «Әлмәт шәһәре район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесе (килешү буенча) |
| 15. | «Сервис компаниясе Акмаль» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 16. | "Сервис компаниясе Альянс" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 17. | "Римера-Алнас" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 18. | «Әлмәт җылылык челтәрләре» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) |

| 1 | 2 |
|---|---|
| 19. | «Әлмәт-Водоканал» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) |
| 20. | «Кадрлар үзәге» укыту-курс комбинатының җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 21. | Шәхси эшмәкәр Федорова Олеся Владимировна (килешү буенча) |
| 22. | "Сервис үзәге" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 23. | Шәхси эшмәкәр Сәгыйдуллина Айсылу Тәлгать кызы (килешү буенча) |
| 24. | "Татнефть-УРС" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 25. | «Аудитсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 26. | «Чишмә» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (килешү буенча) |
| 27. | «Татнефть» ГАЖ (килешү буенча) |
| 28. | «СМП-Нефтегаз» акционерлык җәмгыяте (килешү буенча) |

Район
Башкарма комитеты җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов